***Март –май, 2021***

# *Гимназия сулышы №3*

***25 нче гимназия укучылары газетасы***

*2021 ел Татарстан президенты Миңнеханов Р.Н. указы нигезендә Татарстанда туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде.*

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В ТАТАРСТАНЕ
2021
ТАТАРСТАНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

## Ватан сакчылары көненә карата

Ел саен февраль-хәрби –патриотик чараларга бай була. Бу айлык “Ватан сакчысы булу- һәр кешенең гражданлык позициясе”темасына сыйныф сәгате үткәрү белән башланып китте.







Башлангыч сыйныф укучылары “Минем әтием – солдат” дигән плакатлар ясадылар. 10—11нче сыйныф укучылары хәрби военкомат вәкиле Фәйзрахманов Р.Р.белән очраштылар.



9-11нче сыйныфлар арасында волейбол ярышы үткәрелде.

Традиция буенча 16 нчы февральдә 9-11 нче сыйныфларның жыр белән атлап йөрү смотры булып үтте. Тантаналы рәвештә Россия һәм Татарстан Дәүләт гимннары яңгырады һәм жирәбә буенча һәр сыйныф строй белән хәрбиләрчә атлап үтте. Жюри составында гимназиянең укыту эшләре урынбасарлары: КамалиеваН.И, Мишина В.Б., Гарипова Р.Р. ,Әфган сугышы ветераны, запастагы майор Данилов П.Б. бар иде.
Барлык чыгышларны караганнан соң: 11А сыйныфы 1-урынны, 10 А -2 урынны алды. 3-урынны 11 Б һәм 9 Г сыйныфлары бүлеште. “Иң яхшы командир” исеменә 9 В сыйныфыннан Нестерова Динара лаек булды. Гимназия кунагы- жюри әгъзасы
Данилов Павел Борис улы укучыларның яхшы әзерлек күрсәтүләрен билгеләп үтте.” Командирлар арасында кызлар булуы сөендерә, “-диде ул һәм Ватан сакчылары көне уңаеннан чарада катнашучыларны бәйрәм белән котлады.

## Күпмилләтле Татарстан



5 Б сыйныфы өчен ике команда арасында квест –уен оештырылды. 2021 ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар елы , шуңа да викторина сораулары Татарстан турында һәм анда яшәүче татар,рус, чуваш, мари, удмурт, мордва халыкларының тормыш-көнкүреше , милли киемнәре, бәйрәмнәре иде. Туган тел һәм әдәбияты укытучысы Шарапова Н.Н. укучыларга Татарстан турында тәкъдим иткән башваткычны чишкәндә яхшы әзерлек күрсәттеләр. Квест - уенда“Зирәкләр” командасы җиңүче булды. Титова Валерия

## Спорт белән янәшә

***Йөзү*** *— иң массакүләм һәм популяр спорт төрләренең берсе. Европа һәм дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарында ул уйнатылучы медальләр саны буенча җиңел атлетикадан гына калыша. Археологик табылдыклар раслаганча, безнең эрага кадәр берничә мең ел алдан ук Мисыр, Әссүрия һ.б. дәүләтләрдә яшәүчеләр төрлечә, шул исәптән, хәзерге кроль һәм брасска охшаш стильләрдә йөзә белгән.*

Галиәхмәтов Игорь 7нче г сыйныфында «4» һәм «5» билгеләренә укый, аеруча информатика, биология, физика фәннәрен ярата. Ул 7 яшьтән «Дуслык» спорткомплексында йөзү белән шөгыльләнә. Аңа берничә сорау бирергә булдым.

- Игорь, син ни өчен йөзү спортын сайладың?

-Сәламәт булу өчен. Йөзү ул организмны киеренкелектән арындыра, мускулларны ныгыта, йөрәк эшчәнлеген яхшырта.

- Нинди стильдә йөзәсең?

- Кроль, брасс, баттерфляй, аркада йөзү кебек стильләрне беренче елларда үзләштердем. Йөзү буенча «Олылар» разрядым бар, медальләрем күп. Шәһәр күләмендә, декабрьдә команда составында Казанда сайлап алу ярышларында катнаштым һәм йөзүдән ГТО нормаларын тапшырдым.



- Игорь, яшьтәшләреңә нинди киңәшләр бирер идең?

- Сәламәтлеге турында кеше үзе кайгыртырга тиеш. Көндәлек режимны үтәү кирәк. Сыйныфташларыма, гимназия укучыларына бассейнга ешрак йөрергә киңәш итәм.

- Игорь, уңышлар телим сиңа!
-Рәхмәт!
Бакирова Алия

## Булдырасыз, укучылар!

Гыйнвар аенда Республика күләмендә фәннәр буенча Бөтенроссия олимпиадаларында гимназия укучылары нәтиҗәле урыннар яулады. Менә алар: Исанаева Азалия ( 10 нчы А сыйныфы) рус әдәбияты буенча Бөтенроссия олимпиадасының региональ этапта призёр, Галимова Ева (10 нчы А сыйныфы) рус теле буенча призёр, Данилова Дарья (9 нчы Б сыныфы) һәм Пшеворская Валерия (8 нче А сыйныфы) дөнья күләм сәнгате буенча призёр, Фазлиев Раиль (8 А сыйныфы) геология буенча призёр булдылар, Диплом белән бүләкләнделәр.

Укучыларны чын күңелдән җиңүләре белән котлыйбыз! Бу урында гимназия укытучылары - Казакова Әлфия Фатыйх кызына рус теле һәм әдәбияты укытучысы, Пшеворская Светлана Германовна – музыка укытучысы, Агафонова Надежда Григорьевнага авыр һәм мактаулы хезмәтләрендә уңышлар телибез. Хуҗҗәтов Адель

## Туган тел көне

**Сөйләшсәк тә төрле төрләрдә,**
**Без яшибез Татарстанда...**
*Минемчә, һәр кешегә туган теле газиз.*
*Нинди генә булмасын - украин телеме, чувашмы, мари, я татармы, бәлки, рус теледер....*
*Туган тел – һәркем өчен горурлык билгесе булырга тиеш, һәм һәркем аны сакларга, якларга бурычлы!*

Быел “ Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы”нда әлеге сүзләр бик актуаль яңгырый. 17 февраль көнне гимназия укучылары актлар залында бәйрәмгә җыелды. Төрле милләт



вәкилләренең милли киемнәрен кигән укучы кызлар һәм малайлар рус,татар, чуваш, украин, телләрендә шигырьләр сөйләде, җырлар җырлады, “Бию ритмнары”хореография ансамбле дәртле биюләр башкарды.

Чарага чакырылган кунаклар исеменнән «Кама таңнары» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы, шагыйрә Рәмзия Вәлиева чыгыш ясады. Ул залда утыручыларны Туган тел көне белән котлады һәм аларны туган телләрен өйрәнүдә зур уңышлар теләде .



Минемчә,чарада катнашкан һәр кешенең үз туган теленә карата аралашу чарасы буларак та, рухи тәрбия чарасы буларак та горурлык хисе кичергәндер.
Алексеева Лариса

## Тукай безнең күңелләрдә

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның 135 еллыгына карата шигырь сөйләүчеләр конкурсы биел да китапханәдә узды. 1-11 сыйныф укучылары татар, рус һәм инглиз телләрендә Тукай шигырьләрен сәнгатьле итеп башкардылар.



Жюри әгъзасы гимназиянең китапханәчесе Резедә Вәзир кызы Зәйдуллина укучыларның шигырьләрне зур осталык белән сөйләвен әйтте. 1-урын 3А сыйныфы укучылары Борһанова Адилә һәм Гыйззәтллин Шамилгә,8 Б сыйныфы укучысы Никонова Ангелинага, 2-урын 3 В сыйныфы укучысы Баязитов Эмильгә һәм 5 Б сыйныфы укучысы Гайфетдинов Инсафка, 3-урын 4 В сыйныфы укучысы Әхмәтшин Румилгә һәм 5 Б сыйныфы укучысы Иванова Каролинага бирелде.



Шигырь бәйгесендә катнашучы һәр укучы Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## Соңгы звонок

22 май көнне гимназиянең 9 һәм 11 сыйныф укучылары өчен соңгы кыңгырау чыңлады.
Укучыларны бәйрәм белән котларга гимназия укытучылары, шәһәр администрациясе вәкилләре, әти-әниләр килгән иде.



«Бүген сезнең тормышта – күңелле дә, моңсу да көн. Гимназиядә уку дәверендә сез шактый белем-тәҗрибә тупладыгыз. Сезнең янәшәгездә әти-әниләрегез, укытучыларыгыз булды. Сезгә алда торган бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы биреп, үзегез теләгән уку йортына керүгезне телибез. Хыялларыгыз тормышка ашсын, ак юл сезгә, кадерле укучылар!» -диде котлау чыгышында гимназия директоры Гаранина Светлана Владимир кызы.



Укучылар башкаруында «Мәктәп вальсы»ннан соң чыгарылыш сыйныфлар өчен соңгы кыңгырау яңгырады…
Кадерле укучылар, тормыш юллары сезне кая алып барса да, гимназияне, белем биргән укытучыларыгызны онытмагыз!
Хуҗҗәтов Адель

## Истәлеккә - агач

9 Д сыйныфы укучылары гимназия территориясендә истәлеккә чыршы үсентесе утырттылар. Чыршы агачы тавыш йота торган ылыслы агачлардан санала. “Гимназия янында зур юл булуын да исәпкә алдык,”- диде сыйныф җитәкчесе Шарапова Нурия Нәҗип кызы.



Гимназия тирәсен яшелләндерүгә шулай үзләреннән өлеш кертте чыгарылыш сыйныф укучылары. Волкова Ксения

## Хуш, мәктәп!

Гөрләп узды мәктәп елларыбыз,
Бик тиз җитте аның азагы.
Бүген безнең бәгырьләрне өзә,
Кыңгырауның моңлы авазы.

Чәчкә кебек бала чагыбызда,
Мәктәп булды күмәк йортыбыз
Изге җанлы укытучыларны,
Күңел түребездә йөртербез...

Чын йөрәктән котлавыбыз
Җыр булып сезгә барсын!
Бүгенге бәйрәм гомергә
Истәлек булып калсын!

## Рәхмәт, сезгә, укытучылар!

Белем сукмакларыннан атлап бара торгач, кире кайтмас 11 көз, кыш, яз һәм җәй айлары үтеп, күңелебездә онытылмас хатирә булып уелып калыр.

Безнең тормышыбыз, тәртибебез һәм укуыбыз өчен янып-көеп йөрүче, һәр адымыбызны күзәтеп, ялгышлардан саклаучы укытучыларыбыз, мәктәп елларында безгә терәк, кирәк чакта язгы җилдәй йомшак, ә кайчагында кырыс та булдыгыз. Безнең киңәшчебез һәм сердәшчебез булдыгыз.Сезнең акыллы киңәшләрегезне, үгет-нәсихәтләрне беркайчан да исебездән чыгармабыз!

Фәйзрахманова Рузилә , Заһитова Зәринә



**Кадерле укучыларыбыз!**

**Әгәр сезнең безгә тәкъдим итәрлек яңалыкларыгыз булса хәбәрләрегезне [302001035@edu.tatar.ru](mailto:302001035@edu.tatar.ru) электрон почтасына җибәрегез!**
**Редактор Хуҗҗәтов Адель.**
**Проект җитәкчесе Шарапова Н.Н.**

**Хужҗәтов Адель. Проект җитәкчесе Шарапова Н.Н.**

**Кадерле укучыларыбыз!**
**Әгәр сезнең безгә тәкъдим итәрлек яңалыкларыгыз булса хәбәрләрегезне 302001035@edu.tatar.ru электрон почтасына җибәрегез! Редактор**